СОВЕТ
АПАЗОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д. 18, с.Апазово,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АПАЗ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 18 йорт, Апаз авылы,
Арча муниципаль районы, 422006

Тел. (84366) 94-2-37, факс (84366) 94-2-37. E-mail: Apaz.Ars@tatar.ru

**Апаз авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**« 26 » гыйнвар 2016 ел** **№ 30**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Апаз авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, “Референдум үткәрү инициативасы турында” 2016 елның 22 гыйнварындагы 29 номерлы Апаз авыл җирлеге башкарма комитеты карары нигезендә Апаз авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 13 мартына Апаз авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

«2016 елда Апаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 150 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Күмү урыннарын карап тоту | - Апаз авылы зираты крәшен) коймаларын алыштыру;<br>- Апаз авылыннан 4 км төньяк-көнчыгышка таба урнашкан(элеккеге Шомбаш торакпункты) гамәлдә булмаган зират коймасын төзү. | 30000<br><br>10000 |
| 2 | Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру | Кзыл-Игенче авылында кое ремонты; | 8100 |
| 3 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - юлларга таш салу:<br><br>Апаз авылы (Ленин урамы, Тукай урамы, Совхоз урамы, Гагарин урамы, Базар урамы)<br><br>Пөшәңгәр авылы (Һ.Әһлиуллин урамы, Нагорная урамы, Чапаев урамы)<br><br>Миржәм авылы (Мәскәү урамы, Н.Сафин урамы, Профсоюз урамы)<br><br>Каратай авылы (Г.Камал урамы, Һ.Таткташ урамы)<br><br>Хәсәншәех авылы (каты көнкүреш калдыклары җыелган урынга килү юлы) | <br><br>66100<br><br>66800<br><br>42000<br><br>21000<br><br>111000 |
| | | Барлыгы: | 355000 |

әйе юк

30



3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында яисә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга: Татарстан Республикасы, Арча районы, Апаз авылы, Совет урамы, 19 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Хәсәншәех авылы, Космонавтлар урамы, 20 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Миржәм авылы, Н.Сафин урамы, 36 йорт; Татарстан Республикасы, Арча районы, Пөшәңгәр авылы, Чапаев урамы, 42А йорты, Чапаев урамы, 33 йорт.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Садиков

СОВЕТ АПАЗОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ